# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Гаилә кодексына**
**үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 105 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“105 статья. **Алиментларны индексацияләү**

Суд карары буенча акчалата суммада түләтелә торган алиментларны индексацияләү Россия Федерациясе Гаилә кодексының 117 статьясы нигезендә башкарыла.”;

2) 116 статьяда:

а) 1 өлештә:

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9) шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (психиатрия стационарына законсыз урнаштырудан, яла ягудан һәм хурлаудан тыш), шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә каршы, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен хөкем ителүе булган яисә хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә дучар булучы яисә дучар булган затлар (реабилитацияләү нигезләре буенча үзләренә карата җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш);”;

түбәндәге эчтәлекле $9^{1}$ пункт өстәргә:

"9[1]) авыр яисә аеруча авыр җинаятьләр өчен кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган затлар;";

түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

"11) әлеге статьяның 6 – 10 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә әзерлек узмаган затлар (баланың якын туганнарыннан, шулай ук уллыкка алучы яисә элек уллыкка алган булган һәм үзләренә карата уллыкка алу юкка чыгарылмаган затлардан тыш).";

б) 2 өлештә "7 һәм 10 пунктларында" сүзләрен "7, 10 һәм 11 пунктларында" сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә "7 һәм 10 пунктларында" сүзләрен "7, 10 һәм 11 пунктларында" сүзләренә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле 6 – 10 өлешләр өстәргә:

"6. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган программа буенча һәм тәртиптә бу затларны психологик-педагогик һәм хокукый яктан әзерләү максатларында гамәлгә ашырыла.

7. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасының эчтәлегенә карата таләпләр һәм Россия Федерациясе территориясендә шундый әзерлекне узу турындагы таныклык рәвеше Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана.

8. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләүне оештыру Татарстан Республикасы бюджетында шул максатлар өчен карала торган акчалар исәбеннән һәм чикләрендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган һәм Россия Федерациясе гражданы булып торучы баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар яисә Россия Федерациясе территориясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан үзләре даими яши торган дәүләт территориясендә тематикасын исәпкә алып һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасы эчтәлегенә карата әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән таләпләрдә каралганнан кимрәк булмаган күләмдә тиешле әзерлек узуы турында документлар тапшырылырга мөмкин.

10. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар яисә Россия Федерациясе территориясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары үзләре даими яши торган чит дәүләт территориясендә мондый әзерлекне узмаган очракта, күрсәтелгән әзерлек Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 статьясы нигезендә уздырыла.";

3) 134 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Бары тик балигъ яшьтәге хокуктан файдалануга сәләтле затлар гына опекуннар (попечительләр) булып билгеләнә алалар. Түбәндәгеләр опекуннар (попечительләр) булып билгеләнә алмыйлар:

1) ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән затлар;

2) шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (психиатрия стационарына законсыз урнаштырудан, яла ягудан һәм хурлаудан тыш), шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә каршы, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен хөкем ителүе булган яисә хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә дучар булучы яисә дучар булган затлар (реабилитацияләү нигезләре буенча үзләренә карата җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш);

3) авыр яисә аеруча авыр җинаятьләр өчен кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган затлар;

4) әлеге Кодексның 116 статьясындагы 6 – 10 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә әзерлек узмаган затлар (балаларның якын туганнарыннан, шулай ук балаларның опекуннары (попечительләре) булып торучы яисә булган һәм үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны үтәүдән читләштерелмәгән затлардан тыш).”;

б) 3 өлештә “сәламәтлеге буенча” сүзләреннән соң “(әлеге Кодексның 116 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты)” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, аның 1 статьясындагы 2 пунктының “а” пунктчасындагы алтынчы һәм җиденче абзацларыннан, “б” – “г” пунктчаларыннан, 3 пунктының “а” пунктчасындагы алтынчы абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының “а” пунктчасындагы алтынчы һәм җиденче абзацлары, “б” – “г” пунктчалары, 3 пунктының “а” пунктчасындагы алтынчы абзацы 2012 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законда каралган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 15 июне
№ 38-ТРЗ